Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Түбән Өскебаш авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

05.11. 2021 ел №17

«Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлегенең Красная Гора авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1. 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2021 елның 17 ноябренә 9 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлегенең Красная Гора авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Красная Гора авылы, Дружба урамы, 64 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары, 18 яшькә хәтле 4 һәм аннан артык бала булган күп балалы гаиләләр, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлегенең Красная Гора авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны Югарыдәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Красная Гора авылында юлларны кыш көне карап тоту (кардан чистарту, түгү), проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

- видеокамералар алу (сатып алу) һәм урнаштыру, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

- Красная Гора авылында урнашкан артезиан скважиналарына насослар сатып алу;

-Су башняларына койма тоту( материал сатып алу, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

-Красная Гора авылындагы чишмәне ремонтлау: материал сатып алу, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү

-янгын сүндерү машинасына запчастләр сатып алу; кую: янгын сүндерү машинасына ремонт ясау; проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү?

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Түбән Өскебаш авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм хокукый информация порталында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Түбән Өскебаш авыл җирлеге башлыгы: Н.М. Мөхәммәтҗанов